КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 13 август г.Казань № 596

«Газүткәргечне 16:19:200106:552 кадастр номерлы җир кишәрлеге чигенә кадәр тапшыру. Адресы: ТР, Зәй районы, Иске Маврина авыл җирлеге»« төбәк әһәмияттәге газ белән тәэмин итү системасының линия объектын төзү максатларында гавами сервитут билгеләү турында .

Россия Федерациясе Җир кодексының V[7] бүлеге, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсе арасында газ куллана торган җиһазларны һәм капиталь төзелеш объектларын тоташтыру (технологик тоташтыру) турында 2023 елның 18 августындагы 2400-100714-ТП номерлы шартнамә белән, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (ИНН 16000036, ОГРН 1021603624921) үтенече нигезендә, «Газүткәргечне 16:19:200106:552 кадастр номерлы җир кишәрлеге чигенә кадәр тапшыру. Адресы: ТР, Зәй районы, Иске Маврина авыл җирлеге»« төбәк әһәмияттәге газ белән тәэмин итү системасының линия объектын төзү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Газүткәргечне 16:19:200106:552 кадастр номерлы җир кишәрлеге чигенә кадәр тапшыру. Адресы: ТР, Зәй районы, Иске Маврина авыл җирлеге»« төбәк әһәмияттәге газ белән тәэмин итү системасының линия объектын төзү максатларында кушымта нигезендә җир кишәрлекләренә карата (алга таба - җир кишәрлекләре) 10 елга гавами сервитут (алга таба - гавами сервитут) билгеләргә.

2. Карарга теркәлгән «Газүткәргечне 16:19:200106:552 кадастр номерлы җир кишәрлеге чигенә кадәр тапшыру. Адресы: ТР, Зәй районы, Иске Маврина авыл җирлеге»« төбәк әһәмияттәге газ белән тәэмин итү системасының линия объектын төзү максатларында гавами сервитут чикләре урнашкан урынның график тасвирламасын расларга.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

гавами сервитут иясе – «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

гавами сервитут өчен түләүне исәпләү һәм кертү тәртибе Россия Федерациясе Җир кодексының 3946 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла;

җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә алардан файдалану мөмкин булмаячак яки шактый авыр булачак срогы – бер елга кадәр.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарның күчермәләрен «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә җибәрүне.

5. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән гавами сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзүне;

җир кишәрлекләрен алардан рөхсәт ителгән файдалануның төре нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясындагы 8 пунктында билгеләнгән вакытта файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне;

гавами сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын Россия Федерациясе Җир кодексының 3950 статьясындагы 9 пунктында билгеләнгән срокларда сүтүне.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин